ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51,e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

Постановление
№ 193

Карар
от «22» марта 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәренең Көньяк микрорайонында
линияле объект территориясен ызанлау һәм
планлаштыру проектын әзерләү хакында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 маддәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә , Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Көньяк микрорайоны чикләрендә урнашкан М. Әүхәдиев, Әхмәдиева , Бәдәйле, Олы юл урамнары, Олы юл тыкырыгы, Ак. Вәлиев, Чуйков, Алгы урам, Мөхетдинов, Королев, Короленко, Осинина, Каен җиләге, Җиңүнең 70 еллыгы, Т. Степанова, Х. Вафин, Чишмәле, Көньяк урамнарына газүткәргеч үткәрү линияле объектны ызанлау һәм планлаштыру» проектын әзерләү эшләрен башларга.

2. Әлеге карарны районның «Нократ» («Вятка») газетасында, интернет мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Дәлмиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гарипов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОГРН 1051655091090 ИНН1626008865